РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

___26.03.2019_____ № 272-п

“2018-2022 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү” муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең “2018-2022 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү” муниципаль программасын раслау турында 2018 елның 23 гыйнварындагы 53-п номерлы карары белән расланган “2018-2022 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы балалар һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү” муниципаль программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Программа паспорты таблицасында “Программаны финанслау күләмнәре” 7 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре | 2018-2022 елларда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 3 050,712 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2018 ел – 510,712 мең сум;<br>2019 ел – 635,000 мең сум;<br>2020 ел – 635,000 мең сум;<br>2021 ел – 635,000 мең сум;<br>2022 ел – 635,000 мең сум.<br>Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк. |

»;

1.2. Программаның 7 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Программаны ресурс белән тәэмин итү

2018-2022 елларда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 3 050,712 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

2018 ел – 510,712 мең сум;

2019 ел – 635,000 мең сум;
2020 ел – 635,000 мең сум;
2021 ел – 635,000 мең сум;
2022 ел – 635,000 мең сум.

Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк».

1.3. Программаның 1 нче Кушымтасын әлеге карарның 1 нче Кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**2.** Әлеге карарны информацион-телекоммуникацион “Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресындагы Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://saby.tatarstan.ru адресындагы Саба муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

**3.** Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе И.Р. Гариповка йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Р.Ишниязов

Кушымта №1
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
26.03.2019 №272-п

Кушымта № 7
“2018-2022 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү” муниципаль программасына

# “2018-2022 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы балалар һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү” Муниципаль программасының төп чаралары

| № ч/б | Чаралар исемлеге | Үткәрү вакытлары | Җаваплы башкаручылар | Программаны еллар буенча финанслау күләме, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 |
| **1. Оештыру чаралары** | | | | | | | | |
| 1.1. | Саба муниципаль районы балалар һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча ведомствоара комиссия утырышы (Кушымта №2) | кварталга 1 тапкыр | Ведомствоара комиссия әгъзалары | | | | | |
| 1.2. | Район гомуми белем бирү мәктәпләренең укыту-методик һәм матди-техник базасын ныгыту | даими рәвештә | Мәгариф идарәсе | | | | | |
| **2. Яшь гражданнарга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә эшчәнлекне камилләштерү** | | | | | | | | |
| 2.1. | Балаларга һәм яшьләргә әхлакый һәм патриотик тәрбия бирү буенча семинарлар оештыру һәм үткәрү | ел саен | Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | | | | | |
| 2.2. | Бөек Ватан сугышы, тыл хезмәтчәннәре турында китаплар буенча уку конференцияләре үткәрү. Рефератлар һәм иҗади эзләнү-тикшеренү эшләре әзерләү. | ел саен | Мәгариф идарәсе | | | | | |
| 2.3. | Паспорт тапшыру буенча “Россия паспорты көне” яшьләр-патриотик акциясе үткәрү | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Россия Федерациясе Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Саба районындагы бүлекчәсе | | | | | |
| 2.4. | Җәмәгать тәртибен саклау буенча формированиеләрнең матди базасын ныгыту | ел саен | МО МВД РФ «Саба», Яшьләр | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | эшләре һәм спорт бүлеге | | | | | |
| 2.5. | “Гражданлык һәм патриотизм сәгате” республика акциясен үткәрү | кварталга 1 тапкыр | Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | | | | | |
| 2.6. | Районның һәм республиканың танылган якташлары, тарихы һәм туган якны өйрәнү буенча экспозицияләр циклын оештыру “Ватаныбызны ачып, үзебезне таныйбыз” | ел саен | Башкарма комитетның мәдәният бүлеге, туган якны өйрәнү район музее, Мәгариф идарәсе | | | | | |
| 2.7. | Тарих-туган якны өйрәнү музейларында, мәгариф музейларында экскурсияләр үткәрү һәм катнашу | ел саен | Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | | | | | |
| 2.8. | Җәмәгать тәртибен саклау буенча мәктәп формированиеләренең республика слетында катнашу | ел саен | Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, МО МВД РФ «Саба» | | | | | |
| 2.9. | Балигъ булмаганнарның хокук бозуларны профилактикалау отрядларын үстерү буенча эш | ел саен | Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе, МО МВД РФ «Саба» | | | | | |
| 2.10. | Кадет сыйныфының уңышлы эшендә ярдәм итү | ел саен | Мәгариф идарәсе | | | | | |
| **3. Патриотик тәрбия бирү һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру чаралары, балалар һәм яшьләр арасында спорт чаралары** | | | | | | | | |
| 3.1. | Көзен һәм язын хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле чакырылучыларның республика спартакиадасында катнашу һәм үткәрү. | ел саен | Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | | | | | |
| 3.2. | Биш көнлек хәрби-кыр җыеннары үткәрү | ел саен | Мәгариф идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | | | | | |
| 3.3. | Саба муниципаль районының хәрби хезмәткә алынучылар арасында хәрби-гамәли спорт төрләре буенча район, зона ярышларында катнашу һәм үткәрү | Апрель, Октябрь ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | | | | | |
| 3.4. | Совет гаскәрләрен Әфганстаннан чыгаруга багышланган чаралар үткәрү | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Мәгариф идарәсе, Татарстан | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | | | | | |
| 3.5. | Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр оешмалары спартакиадасы үткәрү | Апрель, Октябрь ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Мәгариф идарәсе, МО МВД РФ «Саба» | | | | | |
| 3.6. | Армиягә чакырылучыларны физик әзерләү буенча мәгариф учреждениеләренең смотр-конкурсларын үткәрү | Февраль-Март ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | | | | | |
| 3.7. | Хәрби хезмәткә чакырылучылар көнен үткәрү | Апрель, Октябрь ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | | | | | |
| 3.8. | Район спорт ярышлары үткәрү:<br>- волейбол буенча<br>- милли көрәш буенча;<br>- танылган спортчы-якташлар бүләгенә, сугышчы-интернационалистларны искә алуга багышланган<br>– якташларыбыз-Советлар Союзы Геройлары истәлегенә багышланган һ.б. | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | | | | | |
| 3.9. | Спортның техник төрләрен үстерү (хәрби-гамәли төрләре) | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Мәгариф идарәсе, Татарстан | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | | | | | |
| 3.10. | Җиңү көнен бәйрәм итүгә багышланган чаралар үткәрү | Май, ел саен | Все участники программы | | | | | |
| 3.11. | Район уку йортларында Бөек Ватан сугышы ветераннары, локаль сугышчылар тыл ветераннары белән хәрби дан көннәренә (Җиңү көннәренә) багышланган батырлык дәресләре үткәрү, очрашулар оештыру | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | | | | | |
| 3.12. | Хәрби дан һәйкәлләре һәм мемориаллары патронажы | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | | | | | |
| 3.13. | “Аҗаган” хәрби-патриотик уенын үткәрү | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге | | | | | |
| 3.14. | Якташларның хәрби һәм хезмәт батырлыклары турында материалларны өйрәнү һәм җыю эшен оештыру | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | | | | | |
| 3.15. | Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (мәктәп) оешмаларының район һәм республика конкурсларын үткәрү һәм катнашу | ел саен | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, Мәгариф идарәсе | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | **НӘТИҖӘ** | | | **510,712** | **635,000** | **635,000** | **635,000** | **635,000** |
| | **БАРЛЫГЫ** | | | **3 050,712** | | | | |

Файдаланылган кыскартулар:

Мәгариф идарәсе – “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” Муниципаль казна учреждениесе;

Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге;

туган якны өйрәнү район музее - Саба муниципаль районы "Саба үзәкләштерелгән туган якны өйрәнү музее" муниципаль бюджет учреждениесе (туган якны өйрәнү район музее);

МО МВД РФ «Саба» – Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге;